ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 299 от «28» 09 2022 г.

Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр саны» дәрәҗәсен бәяләүгә кирә торган күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

«2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указлары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

Кушымта итеп бирелгән хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр саны» дәрәҗәсен бәяләүгә кирә торган күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын расларга.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә секторына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокук порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче О.Н. Павлов

0000011609

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы
башкарма комитетының
«28» 09 2022 ел, №299 карарына
Кушымта

Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән
«Рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр саны» дәрәҗәсен бәяләүгә
кирә торган күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
җирле үзидарә органы эшчәнлеге **регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Мамадыш муниципаль районы буенча «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты» Татарстан Республикасының эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү федераль күрсәткеченең муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр саны» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау регламенты ( алга таба - Регламент) «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты» Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы буенча югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүнең федераль күрсәткече (алга таба - Регламент) «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуленең эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр саны» күрсәткечен исәпләү методологиясен раслау турында» 2021 елның 2 февралендәге 31 номерлы Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт боерыгы нигезендә эшләнгән һәм

муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр саны» күрсәткече зурлыкларын җыю тәртибен билгели.

Мамадыш муниципаль районында Күрсәткеч зурлыкларын җыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тора.

Күрсәткечнең зурлыклары турында мәгълүмат җиткерүчеләр булып рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләрне бетерү чараларын гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затлар тора.

Күрсәткечнең зурлыклары турында мәгълүмат бирү формасы Регламентның кушымтасына туры килергә тиеш. Муниципаль район буенча берләштерелгән (агрегацияләнгән) мәгълүмат Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты мәгълүматы нигезендә төзелә һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына (алга таба - Министрлыкка) тапшырыла. Бер үк вакытта алынган һәм Министрлыкка тапшырыла торган мәгълүмат Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән мәгълүмат җыюны, мониторинглауны һәм Министрлыкка тапшыруны тәэмин итүче вазыйфаи зат тарафыннан архивка тапшырыла.

## II. Төшенчә аппараты

Регламентта түбәндәге терминнар һәм аларның билгеләмәләре кулланыла.

- Рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр - калдыкларны урнаштыру өчен билгеләнмәгән территория, алар өчен түбәндәге шартларның берсе генә булса да үтәлә: күрсәтелгән территорияләрнең мәйданы 10 кв. метрдан артык; күрсәтелгән территорияләрдә җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру күләме 5 куб метрдан артык;
- Ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр - Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (Росприроднадзор) Идел-Кама регионара идарәсенең, Ветеринар күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (ТР буенча Россельхознадзор) һәм Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан турыдан-туры ачыкланган «рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр» төшенчәсенә туры килә торган территория.
- Рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләрне бетерү - рөхсәтсез барлыкка килгән чүплек критерийларына туры килә торган, Россия Федерациясенең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнары һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге законнар таләпләренә туры китерелгән территория, ул территориядә башкарылган эшләр актлары һәм (яки) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының тикшерү акты белән расланган Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бозылган җирләрне торгызу буенча эшләр һәм (яки) калдыкларны чыгару (территорияләрне чистарту) буенча эшләр тәмамланган.

## III. Мәгълүмат җыю тәртибе, аны бирү вакытлары һәм формалары

3.1 Ике атнага бер тапкыр Министрлык 1 нче таблица формасы буенча Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел-Кама регионара идарәсе, Ветеринар һәм фитосанитар күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Министрлык тарафыннан Мамадыш муниципаль районы территориясендә ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр буенча гомумиләштерелгән мәгълүматны Мамадыш муниципаль районы адресына җибәрә.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы буенча ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр турында мәгълүмат

Таблица 1

| Т.б. номер пп | Хисап чорында ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекнең алдагы хисап чорында фактта урнашкан урыны (почта адресы, географик координаталары, җир кишәрлегенең кадастр номеры/кварталы яисә мәгълүматлар объектын идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган башка белешмәләр) | Территориянең рөхсәтсез барлыкка килгән чүплек алып торган мәйданы. кв.м. | Җитештерү һәм куллану калдыкларын рөхсәтсез барлыкка килгән чүплектә урнаштыру күләме. куб.м. |
|---|---|---|---|
| | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |

3.2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты 2 нче таблицаның 5 нче баганасын тутырып, 1 (чүплек бетерелде), 0 (чүплек бетерелмәде) күрсәтеп, чүплекләрне бетерүне раслый торган фотоматериалларны беркетеп, Министрлык адресына Мамадыш муниципаль районы территориясендә ачыкланмаган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләрне бетерү турында мәгълүмат җибәрә.

Таблица 2

| № | Хисап чорында ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекнең алдагы хисап чорында фактта урнашкан урыны (почта адресы, географик координаталары, җир кишәрлегенең кадастр номеры/кварталы яисә мәгълүматлар объектын идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган башка белешмәләр) | Территориянең рөхсәтсез барлыкка килгән чүплек алып торган мәйданы. кв.м. | Җитештерү һәм куллану калдыкларын рөхсәтсез барлыкка килгән чүплектә урнаштыру күләме. куб.м. | Хисап чорында рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекне бетерү турында мәгълүмат* |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |

Башкарма комитет җитәкчесе _______ / _______/

3.3. Министрлык квартал саен муниципаль берәмлекләрдә хисап чоры ахырына калган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләргә нәтиҗә ясый, шулай ук ел башына теркәлгән ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләрнең гомуми санына карата бетерелгән рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр өлешен исәпли. Бу мәгълүмат Мамадыш муниципаль районы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечен

исәпләгәндә кулланыла. Мамадыш муниципаль районы территориясендә ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләр саны, шулай ук аларны бетерү турында мәгълүмат барлык муниципаль берәмлекләр буенча 3 нче таблица формасы буенча җыелма таблицада тутырыла.

Таблица 3

| Муниципаль район/шәһәр округы | Хисап чорында ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекнең алдагы хисап чорында фактта урнашкан урыны (почта адресы, географик координаталары, жир кишәрлегенең кадастр номеры/кварталы яисә мәгълүматлар объектын идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган башка белешмәләр) | Территориянең рөхсәтсез барлыкка килгән чүплек алып торган мәйданы. кв.м. | Җитештерү һәм куллану калдыкларын рөхсәтсез барлыкка килгән чүплектә урнаштыру күләме. куб.м. | Хисап чорында рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекне бетерү турында мәгълүмат* |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |

***1 - бетерелгән, 0 - бетерелмәгән..**

3.4. Мамадыш муниципаль районы буенча җыелма мәгълүмат квартал саен Министрлык тарафыннан Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетына 4 нче Таблица формасы буенча җибәрелә

Таблица 4

| Дата | Хисап чорында ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекне бетерү планы | Хисап чорында ачыкланган рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекне бетерү факты | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |

Башкарма комитет җитәкчесе ______________ / ______/

Татарстан Республикасы Мамадыш район башкарма комитеты Министрлык адресына Башкарма комитет җитәкчесе имзасы белән чүплекләрне бетерү планы/факты буенча мәгълүматны раслау яисә кире кагу язуы җибәрә.

3.5. Министрлык адресына тапшырыла торган мәгълүматның (белешмәләрнең) эчтәлеге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021

елның 3 апрелендәге 542 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына беркетелгән күрсәткечләр системасы» 5 контурлы моделе нигезендә билгеләнә.